Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение

«Нижневязовская начальная общеобразовательная школа ЗМР РТ»

«Согласовано»

Руководитель МО

_______/ Барскова Ю.А./

Протокол № 1 от

«07» 08 2023 г.

«Утверждаю»

Директор МБОУ «Нижневязовская НОШ» ЗМР РТ

_______ /Салахеева Г.А./

Приказ № 1 от

«07» 08 2023 г.

# Рабочая программа

Учебного предмета, курса, дисциплины (модуля)

МБОУ «Нижневязовская НОШ» ЗМР РТ

Насибуллиной Раисы Рифатовны

Ф.И.О., категория

литературное чтение на родном языке (татарском) 4 класс

предмет, класс.

## Аңлатма язуы

**Эш программасының статусы**

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

1)Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” законы.

2)”Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы”. 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел. Ав.Р,З,Хайдарова,Р.Л.Малафеева

3) “Татар теле һәм әдәбияттан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты” Татарстан Республикасы Фән һәм Мәгариф министрлыгы,Казан,2008.

4).«Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпләрдә татар теле укыту программасы» (рус телендә сөйләшүче балалар өчен )1-4 нче сыйныфлар, Казан, «Мәгариф»нәшрияты, 2011 . Төзүчеләр: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева.

**Эш программасының структурасы**

Татар әдәбиятыннан эш программасы бербөтен документ булып тора.Ул түбәндәге өлешләрдән тора: аңлатма язуыннан, УМК, төп бүлекләрне,белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән,укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләрдән, календарь-тематик планнан, ,әдәбият исемлегеннән

**Умк**

Татар әдәбиятыннан эш программасы рус телендә сөйләшүче балаларны Р.З.Хәйдарованың коммуникатив технология нигезендә татарча сөйләшергә өйрәтү өчен төзелгән укыту-методик комплексына таянып төзелде.

-Дәреслек: Татар теле : Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең.4 нче сыйныфы өчен дәреслек. Р.З Хәйдәрова**;** Казан. Мәгариф. 2014. 2 кисәктә.;

-Программа Россия Федерациясендәге гомуми белем бирү мәктәпләренең базис укыту планы нигезендә төзелгән. Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсендәге законнары нигезендә базис укыту планында Россия Федерациясе субъектларының дәүләт телләрен өйрәнү мөмкинлеге каралган.

-Эш программасы “Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы”на һәм “Үрнәк программа”га нигезләнеп төзелде.Авторлары: Р.З.Хәйдәрова,Р.Л.Малафеева.Программа 2011 нче елда бастырылган.

”Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы” нда 4 нче сыйныф өчен татар теле һәм әдәби уку өчен 102 сәгать каралган . Базис укыту планы буенча 4 нче сыйныфта уку елы 34 атна тәшил итә.

Шуның 34 сәгате- әдәби уку (атнага 1 сәгать). Эш программасы 1 елга төзелде.

**Эш программасының эчтәлеге**

Рус телле балаларга әдәбият дәресләрен укытуның төп максаты: укучыларны татарча аралашырга өйрәтү, лексик, грамматик нигезләрен системалы рәвештә үзләштерү,телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теленә хөрмәт тәрбияләү, бу телнең дәүләт теле буларак әһәмияте зур булуына төшендерү.

Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү сорала:

1. татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү;
2. татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
3. программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
4. карап чыгу, танышу, өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
5. татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;
6. халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү.

Эш программасы тел белеме тармаклары арасында системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык,коммуникативлык принципларын истә тотып

төзелде.
Татар исемнәрен, Татарстанның табигатен, җирлеген, топонимикасын дөрес әйтә белергә өйрәтү, аларның семантикасы белән кызыксындыру, балалар фольклоры, татар халкы авыз иҗаты, әдәбият-сәнгать вәкилләре белән беренчел таныштыру - **башлангыч этапта** танып белү максатының төп эчтәлеген тәшкил итә

Укучыларның кабул итү мөмкинлекләрен исәпкә алып, аралашу-сөйләшү проблемаларына туры килгән әдәби әсәрләрдән төрле өзекләр сайлауны дәреслек авторларына калдыру - методика фәнендә программага эчтәлек сайлауда монополиялектән котылуның бер юлы дип күрсәтелә.

Тел өйрәтү процессында татар теле һәм уку дәресләре үзара шартлы бәйләнештә булалар. Циклда әдәби әсәрне өйрәнү өчен бирелгән сәгатьләр санына татар теле дәресләре саны да, уку дәресләре саны да керә.

## <u>Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр</u>

### Тыңлап аңлау

Төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;

сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;

зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;

Сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

### Диалогик сөйләм

Сорау, җавап, килеш(мә)ү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;

аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү;

парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;

терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү;

татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә белү.

### Монологик сөйләм

Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү;

конкрет ситуациягә үз карашыңны, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;

монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү;

өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләп бирә белү;

өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белү.

### Уку

Программада тәкъдим ителгән текстларны, татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;

текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү;

таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белү;

таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба белү.

### Язу

Өйрәнелгән темалар буенча актив куллануда булган сүзләрне дөрес яза белү;

конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;

прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстлары (шәхси һәм официаль хатлар, котлаулар һ.б.) яза белү;

үзеңне борчыган проблемага карата үз фикерләреңне язмача җиткерә белү;

тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү.

**Татар әдәбиятыннан тематик план 4 нче сыйныф**
**Елга 34 сәгать татар әдәбияты (атнага 1 сәг)**

| **Яңа уку елы котлы булсын! (8 сәг.)** | |
|---|---|
| **Коммуникатив максат** | **Якынча сөйләм үрнәкләре** |
| Беренче сентябрь көне ничек узуы турында сөйли белү.<br>Дәрес әзерли торган эш урыны турында сөйли белү.<br>Көндәлек режимны сөйли белү.<br>Уку хезмәтенә карашы буенча, укучыга бәя бирә белү.<br>Әңгәмәдәшеңнең ничәнче сыйныфта укуын, нинди өй эшләрен әзерләвен, дәрестә нәрсәләр эшләвен сорый белү.<br>Китапханәчедән кирәкле китап турында белешмә ала белү. | Яңа уку елы башланды. Без укытучыларны **яңа уку елы белән** котладык. <...><br><br>Мин тәртип яратам. Минем эш урыны чиста.<br>Алеша иртән сәгать җидедә тора.<br>Оля яхшы укый. Ул - тырыш укучы.<br><br>Дәрестә нишләдең? Мин мисалны дөрес эшләдем, мәсьәләне **дөрес чишмәдем**.<br><br>Сездә кошлар турында китаплар бармы? |
| **Кошлар һәм хайваннар дөньясында (8 сәг.)** | |
| Кошлар, аларны саклау турында әдәби әсәрләр аша сөйләшү.<br>Хайваннар турында сорый һәм белешмә бирә белү. Аларны тасвирлый белү. | Кыш көне кошларга бик салкын. <...> Марат кошларга таш ата. Ул начар**мәрхәмәтсез** малай. <...><br>Аның төсе ... **. Ул ... белән туклана.** Ул кыш көне ... . Ул ... ашый. **Ул ... бирә**. |
| **Кышкы уеннар (3 сәг.)** | |
| Балалар яратып уйный торган спорт төрләрен әйтә, үзеңнең нинди спорт төрен яратканыңны, төрле уеннарда катнашуың турында әйтә, уенга чакыра, уенның вакытын әйтә белү. Уенга барырга кирәклегенә инандыра, бару-бармауның сәбәбен атый белү.<br>Укылган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү, геройларга бәя бирү | Мин хоккей яратам. Мин хоккей уйныйм. Әйдә, хоккей уйныйбыз. Хоккей сәгать унда башлана.<br>Әйдә, урамга чыгабыз. Урамда күңелле, рәхәт, саф һава. Синең чанаң бармы? Минем чанам юк. Миңа чана бир әле. Мин бармыйм, чөнки дәрес әзерлим.<br>Коля – батыр малай,**чөнки** ул **бабайга** абыйсына ярдәм итте. |
| **Минем дусларым (4 сәг.)** | |
| Үзеңнең дустың турында сөйли белү.<br>Кечкенә хикәяләрнең эчтәлеген сөйли, геройларга бәя бирә белү. | Минем дустым бар. Аның исеме –Айсылу. Без аның белән бергә укыйбыз. Без бергә мәктәпкә йөрибез.<br>Ул тырыш, әдәпле, тыйнак. <...> |
| **Дүрт аяклы дусларыбыз (5 сәг.)** | |
| Дүрт аяклы дусларыбызның кыяфәтеләре, гадәтләре турында сөйли белү.<br>Аларга карата үз мөнәсәбәтеңне белдерә белү. | Песиемнең койрыгы йомшак, колаклары кечкенә, күзләре яшел. <...><br>Мин этемне бик яратам, аш бирәм, аның белән урамга чыгам. |
| **Яз килә (3 сәг.)** | |
| Язгы табигать турында сөйли белү.<br>8нче март бәйрәме белән котлый белү.<br>Яз бәйрәме – Карга боткасы турында сөйли белү. | Ямьле, күңелле яз җитте. Елгада боз китә. Җылы яктан кошлар кайта. Без кошларга оя ясыйбыз.<br>Көннәр озын, төннәр кыска була.<br>Кадерле әнием! Сине бәйрәм белән котлыйм. Сиңа сәламәтлек телим.<br>Яз көне матур бәйрәм була. Ул Карга боткасы. Балалар ... <...> |

| Татарстан (1 сәг.) | |
|---|---|
| Татарстанның символикаларын әйтә белү.<br>Казан шәһәре турында сөйли белү.<br>Татарстан шәһәрләре турында сөйләшү.<br>Балалар шагыйрьләре, язучыларының исемнәрен, нәрсә язганын әйтә белү. | Татарстанның нинди дәүләт символлары бар? Дәүләт флагында нинди төсләр бар?<br>Казан бик матур, зур шәһәр. Миңа Казан Кремле ошады. Кремльдә Кол Шәриф мәчете бар. <...><br>Татарстанда нинди шәһәрләр бар? Алабуга Казаннан еракмы?<br>Бари Рәхмәт – шагыйрь. Ул шигырьләр яза. Дәрҗия Аппакова – язучы. Ул хикәяләр яза. <...> |
| **Матур җәй җитә (2 сәг.)** | |
| Җәй көне кая бару турында сөйлешү.<br>Җәйге бакчада хезмәт турында сөйли белү. | Син җәй көне кая барасың? Мин җәй көне авылга барам.<br>Бакчада эшлим. Чүп утыйм, су сибәм. <...> |

Башлангыч этапта өйрәнү өчен тәкъдим ителгән шагыйрьләр һәм язучылар: Г.Тукай, М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Х.Гарданов, Б.Рәхмәт, Ә.Бикчәнтәева, Р.Миңнуллин, Г.Лотфи Җ.Тәрҗеманов, Ш.Галиев, Җ.Дәрзаман, Р.Вәлиева, Д.Аппакова, Р.Корбан, Н.Мадьяров, Г.Рәхим, Х.Халиков, И.Туктар, М.Газизов, Р.Батулла, Р.Мингалим, Р.Фәйзуллин, Г.Бәширов, К.Маховский, Л.Толстой, В.Осеева.

**4 нче сыйныф**

1. Татар телендәге хәреф-аваз системасына анализ бирә белү.
2. Исемнәрнең килеш кушымчаларын сөйләмдә дөрес куллану.
3. Исемнәрне күплек санда тартым белән төрләндерү.
4. **Маратның китабы** төзелмәсен сөйләмдә куллану.
5. Кушма, парлы исемнәрнең мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
6. **Кадәр, соң** бәйлекләре белән таныштыру.
7. Чагыштыру, артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, сөйләмдә куллану.
8. **Монда, анда** күрсәтү алмашлыкларын сөйләмдә куллану.
9. **Мин, син, ул** зат алмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә төрләнешен сөйләмдә куллану.
10. Билгесез үткән заман хикәя фигыльне III зат берлек санда сөйләмдә куллану.
11. Татар һәм рус телләрендә сүз тәртибе үзенчәлекләр белән таныштыру.
12. И**ртәгә эшлим** конструкциясе белән таныштыру

**Орфоэпик һәм орфографик минимум.**

1. Сүз басымы. Аны дөрес куя белүгә ирешү, рус сүзләре белән чагыштырып күрсәтү. Басымлы иҗекләрне һәм сүзләрне дөрес уку һәм матур язу күнекмәләре булдыру.
2. Басымның үзенчәлекле очракларын белү.

2.Сингармонизм законының асылын гамәли үзләштерү.

3.Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү.

4. Орфоэпик һәм орфографик яктан сөйләмне оештыру эшентирәнәйтү.

| Дәрес № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Укучыларның эшчәнлек төре | Контроль төре | Материал үзләштерүнең көтелгән нәтиҗә | Өй эше | Үткәрү вакыты Вакыт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **”Яңа уку елы котлы булсын”- 8 сәг.** | | | | | | | |
| 1 | Белем бәйрәме. Хикәя төзү. | 1 | Парларда эшләү, монологик сөйләү | Монолог төзү | Беренче сентябрь көне ничек узуы турында сөйли белү. | | |
| 2 | С. Маршак “Һәр атнада җиде көн” | 1 | Шигырьне сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру Шигырь яңгырашын ишетү | Әңгәмә үткәрү | Шигырьне сәнгатьле укый белү | | |
| 3 | Х. Гарданов “К хәрефе” | 1 | Шигырьне сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру Шигырь яңгырашын ишетү | Әңгәмә үткәрү | Шигырьне сәнгатьле укый белү | | |
| 4 | Р. Миңнуллин. “Үсми калган хәреф”. | 1 | Шигырьне сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру Шигырь яңгырашын ишетү | Әңгәмә үткәрү | Шигырьне сәнгатьле укый белү | | |
| 5 | “Эш урыны” тексты | 1 | Монологик сөйләү | Сорауларга җавап бирү | Төрле һөнәрләрне танып белү. | | |
| 6 | Сәгать ничә? | 1 | Сәгать ничә? соравына җавап бирү | Сөйләмдә куллану | Сәнгатьле укый белү | | |
| 7 | “Алсу” хикәясе | 1 | Өйрәнгән сүзләр сөйләмдә куллана белү. Текст эчтәлеген сөйли белү | Текст белән эшләү | Диалог, монолог төзү, сөйли белү | | |
| 8 | Г.Тукай “Сабыйга” шигыре | 1 | Текст белән эшләү. Өйрәнгән сүзләр сөйләмдә куллана белү. Текст эчтәлеген сөйли белү | Текст белән эшләү | Диалог, монолог төзү, сөйли белү | | |
| **Кошлар һәм хайваннар дөньясында –8 сәг** | | | | | | | |
| 9 | Ж. Тәрҗеманов “Табигать китабы” шигыре | 1 | Парларда эшләү, монологик сөйләү | Сәнгатьле уку | Ел фасылы билгеләре турында сөйли белү | | |
| 10 | Г. Тукай “Елның дүрт фасылы” | 1 | Шигырьне сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру Шигырь яңгырашын ишетү | Сәнгатьле уку | Шигырьне сәнгатьле укый белү. | | |
| 11 | Г. Гәрәева “Көз һәм балалар җыры”. Дару үләннәре | 1 | Монологик сөйләм. Шигырьне сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру | Сәнгатьле уку | Көз билгеләрен сөйли белү | | |
| 12 | В.Монасыйпов “Шифалы табиблар”. Б. Рәхмәт“Кошлар | 1 | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен активлаштыру. | Сәнгатьле уку | Дару үләннәрнең файдасын белү, аларның исемнәрең белү | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | киткәндә” | | | | | | |
| 13 | Г. Лотфи “”Песнәк белән Әнисә | 1 | Өйрәнгән сүзләр сөйләмдә куллана белү. Текст эчтәлеген сөйли белү | Текст белән эшләү | Диалог, монолог төзү, сөйли белү Хикәяне сәнгатьле укый белү. | | |
| 14 | Җ. Тәрҗеманов “Чирик” хикәясе | 1 | Өйрәнгән сүзләр сөйләмдә куллана белү. Текст эчтәлеген сөйли белү | Текст белән эшләү. | Диалог, монолог төзү, сөйли белү | | |
| 15 | Хайваннар дөньясында. “Тиен”Ә.Кари | 1 | Парларда эшләү, монологик сөйләү | диалог төзү | Хайваннар турында сорый һәм белешмә бирә белү. Аларны тасвирлый белү. | | |
| 16 | Г. Тукай. “Ташбака белән Куян”. “Яшел энәле керпе” әкияте | 1 | План буенча сөйләү Әсәрдәге геройларга бәя бирү, үз фикереңне әйтү | Сәнгатьле уку | Хикәянеңнең эчтәлеген сөйли белү. | | |
| **Кышкы уеннар- 3 сәг** | | | | | | | |
| 17 | Кыш килде. Ә. Ерикәй “Беренче кар”. Г. Бакирдан “Кышкы уен” | 1 | Парларда эшләү, монологик сөйләү | Сәнгатьле уку | Кыш билгеләрен сөйли белү. Шигырьне сәнгатьле укый белү. | | |
| 18 | Б. Рәхмәт. “Яңа ел килгәч”. “Яңа елны ничек бәйрәм итәләр?” тексты | 1 | Парларда эшләү, монологик сөйләү | Хикәя төзү | Яңа ел турында сөйли белү. Бәйрәмдә нишләгәнеңне әйтә белү. Яңа елга багышланган шигырьләрне яттан сөйләү, җырлар җырлау. | | |
| 19 | А.Алиш “Куян кызы”. “Коля” хикәясе | 1 | Текстның эчтәлеген сәнгатьле уку. | Текст белән эшләү | Текстның эчтәлеген сәнгатьле укый белү. | | |
| **Минем дусларым-4 сәг** | | | | | | | |
| 20 | Минем дустым | 1 | Диалогик сөйләү Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен активлаштыру. | диалог төзү | Дус турында сөйли белү | | |
| 21 | Г. Бәширов. “Сылтау”. | 1 | План буенча сөйләү Әсәрдәге геройларга бәя бирү, үз фикереңне әйтү | Сәнгатьле уку | Укылган хикәянең эчтәлеген, үзеңнең дустың турында сөйли белү. | | |
| 22 | И. Туктар. “Алма”. Б.Рәхмәт “Минем дуслар” шигыре | 1 | Текстның эчтәлеген сәнгатьле уку. | Текст белән эшләү | Хикәяне сәнгатьле укый белү | | |
| 23 | Д. Аппакова. “Шыгырдавыклы башмаклар”. | 1 | План буенча сөйләү Әсәрдәге геройларга бәя бирү, үз фикереңне әйтү | Сәнгатьле уку | Текстның эчтәлеген сөйли белү. | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Дүрт аяклы дусларыбыз – 5 сәг** | | | | | | | |
| 24 | Р. Мингалим. “Дөньяда бер эт бар иде”. | 1 | Парларда эшләү, монологик сөйләү | диалог төзү | Дүрт аяклы дусларны тасвирлый белү. | | |
| 25 | Г. Тукай “Кызыклы шәкерт” | 1 | Шигырьне сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру Шигырь яңгырашын ишетү | Сәнгатьле уку | Шигырьне сәнгатьле укый белү. | | |
| 26 | Г. Мөхәммәтшин. “Ак песи”. | 1 | Текстның эчтәлеген сәнгатьле уку. | Текст белән эшләү | Хикәяне сәнгатьле укый белү | | |
| 27 | Р. Батулла. “Чикыл белән Мырый”. | 1 | Текстның эчтәлеген сәнгатьле уку. | Текст белән эшләү | Текстның эчтәлеген сәнгатьле укый белү. | | |
| 28 | “Дүрт аяклы дусларым” кабатлау. Тест | 1 | Балаларның белемнәрне күзәтү, ныгыту, бәяләү | Тест | Өйрәнелгән материал белән файдалана белү | | |
| **Яз килә – 3 сәг** | | | | | | | |
| 29 | Яз килә. Р.Вәлиева “Яз”шигыре | 1 | Язучының биографиясен сөйләү | Әңгәмә булдыру | Яз билгеләре турында сөйли белү. 8 нче Март бәйрәме белән котлый белү.Автор турында кечкенә белешмә бирү. | | |
| 30 | Карга боткасы. Л. Толстой. “Әбисе белән оныгы”. | 1 | Сөйләм осталыгын үстерү | Сәнгатьле уку | Текстны сәнгатьле укый белү | | |
| 31 | М. Газизов. “Рәхмәт”. В.Осеева “Дүрт кыз” | 1 | Үз фикереңне әйтү | Әңгәмә булдыр | Итагатьле сүзләрне сөйләмдә куллана белү. | | |
| **Татарстан - 1 сәг** | | | | | | | |
| 32 | Татарстанның дәүләт символлары. Казан – башкалам.. Татарстан шәһәрләре | 1 | Дәүләт символлары белән бәйле лексик берәмлекләрне сөйләмдә куллану | диалог төзү | Татарстан турында кыскача белешмә бирә белү | | |
| **Матур җәй җитә -2 сәг** | | | | | | | |
| 33 | Ш. Галиев. “Җәйге болында”. | 1 | Шигырьне сәнгатьле уку күнекмәләрен булдыру Шигырь яңгырашын ишетү | диалог төзү | Җәй билгеләрен әйтә белү. | | |
| 34 | “Шүрәле”әкияте | 1 | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен активлаштыру | Хикәя төзү | Лексик-грамматик материалны куллана белү | | |